**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ САЛМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 13 апреле** **4№**

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 25 гыйнварындагы « Иске Салман авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау хакында» 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елдагы «Оборона турында» 61-ФЗ номерлы, 1997 елдагы «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизацияләү турында» 31-ФЗ номерлы, 1998 елдагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 53-ФЗ номерлы, 2003 елдагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 719 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 6 февралендәге «Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 103 номерлы карары, Җирлек Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Иске Салман авыл җирлеге» территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта «(3 айдан артык вакытка)» сүзләреннән соң «шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлгәннәре дә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Иске Салман авыл җирлеге»
Башкарма комитет җитәкчесе: А.Р.Хәлиуллин